**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**Верхнестярлинского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Советы**
**БАШЛЫГЫ**

**ул. Советская, д.32г, с. Верхнее Стярле, 423314**
**Азнакаевского муниципального района**
**Тел.факс (8-85592) 42618,**
**VSt.Azn@tatar.ru**

**Совет урамы, 32г, Югары Стәрле авылы, 423314**
**Тел.факс (8-85592) 42-6-18,**
**VSt.Azn@tatar.ru**

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«09» ноябрь 2020 ел № 4

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Түбән Стәрле торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Түбән Стәрле торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 20 ноябрендә билгеләргә.

1.1. Билгеләргә:

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Түбән Стәрле торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Башкарма комитеты;

гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 20 ноябрь 2020 ел 10.00 сәг.тән 11.00 сәг.кадәр;

үткәрү урыны – Түбән Стәрле авылы, Кызыл тан ур. , 42Г йорт, Түбән Стәрле ФАПы.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2021 елда беренче төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Түбән Стәрле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм аны икенче төркем инвалидлар өчен 200 сум итеп билгеләргә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

Түбән Стәрле авылында юлларны кардан чистарту ( килешү буенча түләү) ;

Түбән Стәрле авылында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү ("Яңа ел»," Җиңү көне»,» Сабантуй", "Халыкара өлкәннәр көне»," Инвалидлар көне», бәйрәм чаралары үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтү);

Түбән Стәрле авылында спорт чараларын оештыру һәм үткәрү (спорт инвентарьлары, бүләк һәм сувенир продукциясе сатып алу);

Түбән Стәрле авылы зираты территориясендә контейнер мәйданчыгы урнаштыру (киртәләр алу, койма ясау һәм урнаштыру, контейнер сатып алу, контейнер мәйданчыклары урнаштыру (нигез салу, коймалар урнаштыру).

« РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авылы, Совет урамы, 32г , Түбән Стәрле авылы, Кызыл тан урамы , 42Г йорт , Түбән Стәрле авылы, Кызыл тан урамы 19 йорт адреслары буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
4. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Л.С.Сабирҗанова